**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2024 елның 11 ноябре** **№ 12**

**Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Урэсбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 25 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Урэсбаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Урэсбаш авылы, Пионерская ур., 21 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә..

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Урэсбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; (җәйге вакытта юлларны кардан чистарту һәм территорияләрне чабу; (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; проект-смета документациясе);
- урамнарны яктырту җайланмасы (энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; проект-смета документациясе);
- торак пункт территориясен төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Түбән Үрәс авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы: В. Г. Сәфәров